ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.02.2019 Казан ш. № 18

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 14 ноябрендәге 311 номерлы боерыгы белән расланган Электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелә торган инвестиция ресурсларыннан файдалану өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 14 ноябрендәге 311 номерлы боерыгы (Дәүләт комитетының 2018 елның 16 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелә торган инвестиция ресурсларыннан файдалану өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3

статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматларны кертү Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 1, 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 34, 3426 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 190-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 30, 4571 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2014, 29 декабрь, бастырып чыгару номеры: 0001201412290024, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы субъектларының инвестиция программалары турында» 2009 елның 1 декабрендәге 977 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 49, 5978 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 4, 504 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2012, № 44, 6022 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 27, 3602 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 415 карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата

уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 26 октябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201510260012);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 26 август, бастырып чыгару номеры: 0001201608260025, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастырып чыгару номеры: 0001201702140002);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 18, 2633 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга

салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын (электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә раслана торган шундый программалардан тыш) үтәвен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 7 ноябрендәге 689/пр номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 06.07.2015, №27);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Мәгълүмат ачу стандартлары үтәлүне системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап һәм электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларыннан файдалануны системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисап рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы (алга таба – Россия ФТХнең 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы) (Российская газета, 2014, 4 июнь);

Федераль тарифлар хезмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларыннан файдалану турында хисап формасын раслау турында» 2014 елның 20 февралендәге 202-э номерлы боерыгы (алга таба – Россия ФТХнең 2014 елның 20 февралендәге 202-э номерлы боерыгы) (Российская газета, 2014, 26 март);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары (алга таба – 593 номерлы ТР МК карары)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, 2059 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт җайга сала торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы карары (алга таба – 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы ТР МК карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 7 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 3 октябрь).»;

1.4 пунктта «инвестиция программалары» сүзләреннән соң «, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торучы,» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктның бишенче абзацында «(алга таба – юридик затлар, шәхси эшкуарлар)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7 пунктта:

1.7.2 пунктчаның уникенче абзацында «294-ФЗ номерлы» сүзләреннән соң «һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы» сүзләрен өстәргә;

1.7.2 пунктчада уналтынчы абзацны төшереп калдырырга;

1.8 пункка түбәндәге эчтәлекле 1.8.4 пунктча өстәргә:

«1.8.4. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан федераль округ территориясендә, федераль округлар территорияләрендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен оештыру өлкәсендә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы вәкиле (алга таба – вәкаләтле федераль органы) һәм (яки) алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе идарәче компаниясе вәкиле урынга чыгып уртак планлы тикшерү уздырылганда катнашырга мөмкин.»;

1.9 пунктның 1.9.2 пунктчасындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- 294-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2.3 пунктта:

2.3.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

«2.3.2. Тикшерүне (документар, урынга чыгып) үткәрү вакыты 20 эш көненнән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планлы тикшерү уздыру срогы аны уздыра башлау датасыннан алып иң күбе унбиш эш көне тәшкил итә.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, Дәүләт комитетының урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре нигезендә, урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү вакыты Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата тикшерү уздырганда, тикшерүне уздыручы Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата иң күбе ун эш көненә һәм микропредприятиеләргә карата иң күбе ун сәгатькә.

Кече эшкуарлык субъектына карата урынга чыгып планлы тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурлыгы килеп чыккан очракта Дәүләт комитетының рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, ләкин иң күбе 10 эш көненнән артмаган чорга туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми. Тикшерү үткәрүне туктатып тору чоры гамәлдә булганда кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бүлмәләрендә, бүтән объектларында Дәүләт комитетының күрсәтелгән тикшерүгә бәйле гамәлләре дә туктатып торыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.4 пунктча өстәргә:

«2.3.4. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) ТР Министрлар Кабинетының 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары нигезендә риск-куркынычлы алымны кулланып гамәлгә ашырыла. Планлы тикшерүләрне үткәрү ешлыгы юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә кертүгә карап билгеләнә.»;

2.4 пунктның 2.4.4-2.4.5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.4. Юридик затларны, шәхси эшкуарларны планлы тикшерүләр Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) боерыгы белән Дәүләт комитеты тарафыннан расланган еллык План нигезендә уздырыла.

Ел саен уздырыла торган тикшерүләр планы 294-ФЗ номерлы федераль законга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карарына ярашлы рәвештә, куркыныч-юнәлешле якын килү алымын кулланып эшләнә.

Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда куркыныч-юнәлешле якын килү алымын куллану максатларында, юрилик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге ТР Министрлар Кабинетының 2017 елның 5 августындагы 555 номерлы карарында билгеләнгән критерияләр нигезендә билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертелергә тиеш, әгәр федераль законда яки Россия Федерациясе Хөкүмәте карарында башкача билгеләнмәсә.

Юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеген билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү Дәүләт комитеты тарафыннан, бридик затларның һәм шәхси эшкуарларның зарури таләпләрне үтәмәү ихтималының потенциаль тискәре нәтиҗәләрен исәпкә алып һәм юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның зарури таләпләрне үтәмәү ихтималын бәяләп, гамәлгә ашырыла.

Юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлегенә куркынычлылыкның билгеле бер категориясе бирелмәсә, юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге куркынычның түбән дәрәҗәле категориясенә кертелгән булып санала.

Эшчәнлеге куркынычлылык категорияләренең берсенә кертелгән юридик затның, шәхси эшкуарның соратуы буенча, Дәүләт комитеты мондый сорату килгән датадан башлап 15 эш көненнән артмаган срокта, аларга аларның эшчәнлегенә беркетелгән куркынычлылык категориясе турында мәгълүматны, шулай ук аларның эшчәнлеген куркынычлылыкның билгеле бер категорияләренә керткәндә файдаланылган белешмәләрне җибәрә.

Юридик зат яки шәхси эшкуар Дәүләт комитетына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә аларның эшчәнлегенә элегрәк бирелгән куркынычлылык категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.

2.4.5. Эшчәнлекләренә бирелгән куркынычлылык категориясенә карап, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр үткәрүләр түбәндәге ешлыкта гамәлгә ашырыла:

уртача дәрәҗәле куркынычлылык категориясе өчен – өч елга бер мәртәбәдән ешрак түгел (электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге өлкәләрендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен, – елына бер мәртәбәдән ешрак түгел);

киметүле куркынычлылык категориясе өчен – дүрт елга бер мәртәбәдән ешрак түгел (электр энергетикасы, җылылык белән тәэмин итү, табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге өлкәләрендә эшчәнлекнең җайга

салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен, – ике елга бер мәртәбәдән ешрак түгел);

Эшчәнлеге түбән дәрәҗәле куркынычлылык категориясенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр уздырылмый.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерүне Ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләргә кертү нигезе булып билгеле бер куркынычлылык категориясе өчен билгеләнгән срокның бетүе тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерү тшмамланган көннән башлап.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре**

5.1. Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) зарури таләпләр үтәлешен системалы рәвештә күзәтү, электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларыннан файдаланганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр үтәлешенә анализ ясау һәм аның торышын фаразлау;

б) планлы тикшерүләр уздыруны планлаштыру;

в) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү;

г) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү;

д) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

е) юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү.

Дәүләт функциясен үтәүнең Блок-схемасы шушы Регламентка 4-5 нче кушымталарда китерелде.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы һәм планнан тыш тикшерүләр документар тикшерү һәм (яки) урынга чыгып тикшерү формасында уздырыла.

5.2. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карарында, РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

5.3. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору рөхсәт ителә.

**«Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау» административ процедурасы**

5.4. «Системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау» административ процедурасын башлап җибәрү өчен билгеләнгән тәртиптә расланган инвестиция программасын тормышка ашыра башлау чорының килеп җитүе нигез булып тора.

5.5. Системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны башкарганда Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге гамәлләр гамәлгә ашырыла:

- юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлеген әзерләү;
- документлар һәм материаллар җыю;
- документлар һәм материаллар эшкәртү һәм анализлау;
- системалы рәвештә күзәтү һәм анализ ясау нәтиҗәләре буенча документлар әзерләү.

5.6. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ үткәрү елында инвестиция программалары тормышка ашырылачак юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләрен әзерләү.

Системалы рәвештә күзәтүгә һәм анализлауга тиешле юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләре техник аудит һәм инвестиция программалары бүлеге белгече (алга таба – бүлек белгече) тарафыннан формалаштырыла (әлеге Регламентның 7 нче кушымтасына туры китерелгән форма буенча), Дәүләт комитеты рәисенең эшчәнлекнең тиешле өлкәсенең кураторы булган урынбасары тарафыннан раслана, шулай ук Дәүләт комитетының рәсми сайтында «Белешмә-аналитик материаллар» – «Оешмаларның инвестиция һәм җитештерү программаларын тормышка ашыруга мониторинг» бүлегендә аларны раслаган көннән соң 5 эш көне эчендә урнаштырыла.

Үтәү вакыты: төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) үткәрү чорыннан алдагы елның 1 декабренә кадәр.

Гамәлнең нәтиҗәсе: системалы рәвештә күзәтелергә һәм анализланырга тиеле юридик затларның, шәхси эшкуарларның исемлекләре.

5.7. Документлар һәм материаллар җыю.

Төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметына кагылышлы документларны һәм материалларны җыю юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан дәүләт контроленең предметына кагылышлы дөрес документларны һәм материалларны җитәрлек күләмдә сорату һәм алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

Җыю эше шулай ук юридик затларның, шәхси эшкуарларның «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтларыннан һәм рәсми басма

матбугатлардан дәүләт контроленең предметына кагылышлы мәгълүматларга күзәтү ясау юлы белән дә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат җыю максатларында бүлек белгече тарафыннан куелган сораулар бәян ителгән, системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау кысаларында сорату өчен кирәкле документларның һәм материалларның исемлеген, шулай ук сорала торган документларның һәм материалларның пакетын бирү һәм әзерләү өчен кирәкле срокны үз эченә алган гарызнамә проекты әзерләнә.

Гарызнамәләрнең проектлары техник аудит һәм инвестиция программалары бүлеге башлыгы (алга таба – бүлек башлыгы), Дәүләт комитеты рәисе урынбасары тарафыннан визалана һәм Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) тарафыннан Дәүләт комитеты бланкларында имзалана.

Үтәү вакыты: гарызнамәләрне җибәрү гомуми эш башкару тәртибендә гамәлгә ашырыла, ләкин соңрак түгел:

- хисап кварталы аеның соңгы көненнән – квартал өчен;
- хисап елыннан соң килгән елның 15 мартыннан – ел өчен.

Гамәлнең нәтиҗәсе: җибәрелгән гарызнамәләр.

5.8. Докуметларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау.

Электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларыннан файдалану турында кварталлык хисапларны җыю Дәүләт комитеты тарафыннан системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау процедурасын гамәлгә ашыру өчен аралык мониторингын уздыру максатларында гамәлгә ашырыла.

Алынган (табылган), дәүләт контроленең максатларын һәм бурычларын тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматларны, документларны һәм материалларны җыю нәтиҗәләре буенча бүлек белгече аларны дәүләт контроленең предметы булып торган мәсьәләләрне хәл итү өчен тулы һәм җитәрлек булуын ачыклау предметына эшкәртә һәм анализлый.

Алынган мәгълүмат, документлар һәм материаллар дәүләт контроле предметы кысаларында мәсьәләләрне бөтен яклап һәм тулысынча тикшерү өчен җитәрлек булмаган очракта бүлек башлыгы башлыгы тарафыннан бүлек белгеченә дәүләт контроленең предметына кагылышлы өстәмә мәгълүматны җыю зарурилыгы турында күрсәтмә бирелә.

Үтәү вакыты: дәүләт контроле предметына кагылышлы мәгълүматны, документларны һәм материалларны эшкәртү һәм анализлау төгәлләнергә тиеш:

- алдагы ел өчен – агымдагы елның 1 октябренә кадәрге срокка.

Гамәлнең нәтиҗәсе: аңлатма язуы, анда һәр юридик затка, шәхси эшкуарга карата конкрет нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр була.

Аңлатма язулары системалы рәвештә күзәтү һәм анализлау турында хисапның аерылгысыз өлеше булып тора.

5.9. Системалы рәвештә күзәтү һәм анализ ясау нәтиҗәләре буенча документлар әзерләү.

Мәгълүмат, документлар һәм материаллар җыю, эшкәртү һәм анализлау буенча рөхсәт ителгән һәм кирәкле эшләрнең барлык күләме уздырылу йомгаклары буенча бүлек белгече кирәкле документларны рәсмиләштерә:

системалы рәвештә күзәтү һәм анализ уздырылуы турында хисап һәм аңлатма язуы (Россия ФТХнең 2014 елның 20 февралендәге 201-э номерлы боерыгы белән расланган форма буенча).

Электр энергетикасы өлкәсендә һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләргә (тарифларга) кертелгән инвестиция ресурсларыннан файдалануга системалы рәвештә күзәтү һәм анализ уздырылуы турында хисап бүлек белгече, бүлек башлыгы тарафыннан визалана һәм Дәүләт комитеты рәисенең әлеге юнәлешнең кураторы булган урынбасары тарафыннан бәяләр (тарифлар) билгеләү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр имзалана һәм бәяләр (тарифлар) билгеләү турындагы эшкә теркәлә.

Үтәү вакыты:

- алдагы ел өчен – агымдагы елның 1 ноябренә кадәрге срокка.

Гамәлнең нәтиҗәсе: системалы рәвештә күзәтүне һәм анализлауны үткәрү турында хисап.

**«Планлы тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасы**

5.10. «Планлы тикшерүләр уздыруны планлаштыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен еллык Планны әзерләү срокларының башлануы нигез булып тора.

5.11. Ел саен уздырыла торган тикшерүләр планы, контроль һәм зарури таләпләр бозылуны профилактикалау чараларын уздыру ешлыгы (формасы, дәвамлылыгы, ешлыгы) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеген әлеге Регламентның 2.4 пунктындагы 2.4.4 пунктчасында билгеләнгән тәртиптә куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә кертелүе белән билгеләнә торган куркыныч-юнәлешле якын килү алымын кулланып, административ тәҗрибә бүлеге тарафыннан эшләнә.

Еллык планны әзерләү, шул исәптән аны прокуратура органнарына тапшыру һәм прокуратура органнары белән килештерү тәртибе һәм сроклары, шулай ук еллык планның үрнәк формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карарында билгеләнгән.

Тикшерүләрнең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата тикшерүләр уздыруны үз эченә алган еллык план проекты 473-ФЗ номерлы федераль закон һәм РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары нигезендә килештерү өчен вәкаләтле федераль органга җибәрелә.

Юридик затны, шәхси эшкуарны ел саен уздырыла торган планлы тикшерүләр Планына кертү өчен әлеге Регламентның 2.4 пунктындагы 2.4.5 пунктчада күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

5.12. Административ тәҗрибә бүлеге башлыгы һәр ел саен төзелә торган Планны әзерләү өчен җаваплы башкаручыны (җаваплы башкаручыларны) билгели (алга таба – ел саен төзелә торган Планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы).

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәргән елдан соң килүче елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

5.13. Еллык планны әзерләү буенча җаваплы башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне гамәлгә ашыра:

1) билгеләнгән рәвештә еллык План проектын төзи;

2) аны төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру үзләренең функцияләре булып торучы бүлекләрнең башлыклары, Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәләренең кураторы булып торучы урынбасарлары, Дәүләт комитеты рәисе белән килештерә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 31 августына кадәр;

3) ел саен төзелә торган План проектын карау өчен үзләренә карата планлы тикшерүләрне уздыру планлаштырыла торган юридик затларның, шәхси эшкуарларның урнашкан урыны буенча кәгазьдә (күчермәсен электрон формада теркәп) кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында прокуратура органына җибәрә;

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан алда килүче елның 1 сентябренә кадәр.

Гамәлнең нәтиҗәсе: карау өчен прокуратура органнарына җибәрелгән еллык План проекты.

5.14. Еллык План проекты прокуратура органы тарафыннан каралгач һәм тәкъдимнәр кертелгәч җаваплы башкаручы еллык Планны әзерләү буенча:

1) прокуратура органыннан килгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, еллык План проектына төзәтмәләр кертә;

2) үзгәрешләр кертелгән еллык План проектын төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру үзләренең функцияләре булып торучы бүлекләрнең башлыклары, Дәүләт комитеты рәисенең тиешле эшчәнлек өлкәләренең кураторы булып торучы урынбасарлары белән килештерә;

3) еллык План проектын раслау өчен Дәүләт комитеты рәисенә җибәрә;

4) еллык План Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан раслангач, аны кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) прокуратура органнарына кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә.

Үтәү вакыты: планлы тикшерүләрне үткәрү елыннан соң килүче елның 1 ноябренә кадәр.

Гамәлнең нәтиҗәсе: расланган, прокуратура органнарына җибәрелгән еллык План.

5.15. Җаваплы башкаручы еллык Планны әзерләгәндә Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә расланган еллык Планны Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Үтәү вакыты: еллык Планны Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыра – Татарстан Республикасы прокуратурасы сайтында планлы тикшерүләр уздыруның тиешле расланган бердәм җыелма еллык планы урнаштырылган вакыттан алып 5 эш көне узганчы.

Гамәлнең нәтиҗәсе: Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган еллык План.

5.16. Еллык Планга үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары белән расланган Еллык планнарны әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән очракларда Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә рөхсәт ителә. Еллык Планга кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр алар кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә кәгазьдә (күчермәсен электрон рәвештә теркәп) тиешле кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы рәвешендә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында билгеләнгән тәртиптә тиешле прокуратура органына җибәрелә, шулай ук үзгәрешләр кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла.

**«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы документлар тикшерү үткәрү» административ процедурасы**

5.17. «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен юридик затларны, шәхси эшкуарларны еллык Планга кертү нигез булып тора. Еллык Планны формалаштыру һәм аны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе федераль законнарда билгеләнгән.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы административ гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

- тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
- тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;
- юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерү уздырылуы турында хәбәр итү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.18. Еллык План нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче Дәүләт комитеты бүлекләре башлыклары юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан ун эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.19. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга тикшерүләр Дәүләт комитеты рәисенең (рәис урынбасарының) тикшерү уздыру турында боерыгы нигезендә уздырыла.

Җаваплы башкаручы:

- Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган формада юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы документар тикшерү уздырылуы турында боерык проектын әзерли;

- боерык проектын имза кую өчен Дәүләт комитеты рәисенә (рәисе урынбасарына) юллый.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.20. Җаваплы башкаручы планлы документар тикшерүне үткәрә башлау турында боерык күчермәсен кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы җибәрү юлы белән һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм реестрында, шәхси эшкуарларларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Дәүләт комитетына тапшырылган булса, яисә бүтән үтемле ысул белән юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәреләчәге хакында хәбәр итә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзкөйләнешле оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планлы документар тикшерүне үткәргәндә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлар алдыннан өч эш көненнән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән боерык күчермәсе һәм үзкөйләнешле оешмага (үзкөйләнешле оешма әгъзасына тикшерү уздырылган очракта) җибәрелгән хәбәрләмә.

5.21. Юридик зат, шәхси эшкуар, боерык күчермәсен алган мизгелдән башлап ун эш көне эчендә, Дәүләт комитетына планлы документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә тиеш.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Дәүләт комитетына тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Дәүләт комитеты, тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда, түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратала һәм алалар.

5.22. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар Дәүләт комитеты карамагында булган документлардагы белешмәләр һәм юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылган документлардагы белешмәләр нигезендә:

- белешмәләрнең дөрес булуына карата бәяләү үткәрә;

- документлардагы белешмәләрнең юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге билгеләнгән зарури таләпләргә туры килү-килмәве предметына карата бәяләү үткәрә.

Әгәр дә документар тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырылган документларда хаталар булуы һәм (яисә) каршылыклар, яисә бу документларда булган мәгълүматларның Дәүләт комитетында булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәве ачыкланса, җаваплы башкаручы:

- юридик затка, шәхси эшкуарга, белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән һәм 10 эш көнендә язмача рәвештә кирәкле аңлатмаларны тапшыруын таләп итеп, хат (дәлилле гарызнамә) әзерли;

- хатны (дәлилле гарызнамәне) имза салу өчен Дәүләт комитеты рәисенә (рәисе урынбасарына) җибәрә;

- имзаланганнан соң хатны (дәлилле гарызнамәне) юридик затның, шәхси эшкуарның адресына кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп яисә бүтән үтемле ысул белән (факимиль элемтә, электрон почта, кулга алу турында тамгасы белән кулга тапшырып) җибәрә.

Дәүләт комитетына тапшырылган документларда ачыкланган хаталарга һәм (яки) каршылыкларга карата яисә бу документларда булган белешмәләрнең Дәүләт комитеты карамагындагы документларның белешмәләренә туры килмәвенә карата аңлатмалар тапшыручы юридик зат, шәхси эшкуар Дәүләт комитетына элегрәк тапшырылган документларның төгәл булуын раслый торган документларны өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы.

Элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмалар һәм (яисә) документлар алынганнан соң, тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, элек тапшырылган документларның дөреслеген раслый торган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карап тикшерәләр һәм җаваплы зат тикшерү актын төзи.

Әгәр элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслап тапшырылучы аңлатмалаларны һәм документларны карап тикшергәннән соң, яисә аңлатмалар аңлатмалар булмаганда Дәүләт комитеты зарури таләпләрне бозу билгеләрен билгеләсә, Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары урынга чыгып тикшерү үткәрергә хокуклы, аны үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерүне үткәргәндә алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яки) мәгълүматны таләп итү рөхсәт ителми. Мондый очракта документар тикшерү нәтиҗәсе «Юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасын башкаруны башлау нигезенә туры киләчәк».

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган, карап тикшерелгән аңлатмалар һәм (яки) документлар; зарурлык булганда планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык проекты.

5.23. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы ике нөсхәдә РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү актын төзи.

Тикшерү нәтиҗәсендә бәя билгеләүнең билгеләнгән тәртибе бозылуларны ачыклаган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

- тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган бозуларны тикшерү актында терки;

- үз компетенцияләренә кагыла торган өлештә бозуларны тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган күрсәтмәләрнең проектлары нигезендә, бетерү чорларын күрсәтеп, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында Дәүләт комитетының җыелма күрсәтмәсе проектын әлеге Регламентка 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча әзерли һәм Дәүләт комитеты рәисенә кул кую өчен җибәрә. Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән вакытларда үтәлүен тикшереп тору, бүлек

компетенциясе кысаларында, тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла;

- административ хокук бозу билгеләре ачыкланганда, Дәүләт комитеты вәкаләтләренә туры китереп, административ хокук бозулар турында эшләр кузгата.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә теген куя һәм аны Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затларның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуарлар булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тартуы турында имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы хәбәр Дәүләт комитеты эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын кулга тапшыру турында белдерүле заказлы хат итеп һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында (тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон формада хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булу шарты белән) күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны Дәүләт комитеты

архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклана.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.24. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: мәгълүматны Дәүләт сайтында урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат кертү – билгеләнгән срокларга туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерүне башкару нәтиҗәләре хакында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган һәм бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат.

**«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасы**

5.25. «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга урынга чыгып планлы тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен тиешле юридик затны, шәхси эшкуарны еллык Планга кертү нигез булып тора, шулай ук документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаган очраклар:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдә һәм юридик затларның, шәхси эшкуарларның Дәүләт комитеты карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү» административ процедурасы шушы Регламентның 5.17 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.26. Тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгеләү, урынга чыгып планлы тикшерү үткәрү турында боерык әзерләү, юридик затларга, шәхси эшкуарларга урынга чыгып планлы тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү шушы Регламентның 5.18-5.20 пунктларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.27. Урынга чыгып тикшерү Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан хезмәт таныклыгын күрсәтүдән, юридик затның җитәкчесен яисә бүтән вазыйфаи затын, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) урынга чыгып тикшерүнең билгеләнүе турындагы карары һәм урынга чыгып тикшерүне үткәрүче затларның вәкаләтләре белән, шулай ук урынга чыгып тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контроль буенча чараларның төрләре һәм күләмнәре, урынга чыгып тикшерүгә җәлеп ителә торган экспертларның составы, экспертлык оешмаларының вәкилләре, аны үткәрүнең вакытлары һәм шартлары белән зарури тәртиптә таныштырудан башлана.

Тикшерелергә тиешле затларның таләбе буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары үзләренең вәкаләтләрен раслау максатларында Дәүләт комитеты турында, шулай ук экспертлар, экспертлык оешмалары турында мәгълүмат бирергә бурычлы.

Юридик затның җитәкчесенең, бүтән вазыйфаи затының һәм вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның гозере буенча Дәүләт комитетының вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны контроль буенча чаралар үткәрүнең административ регламентлары һәм аларны юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда файдаланыла торган объектларда үткәрү тәртибе белән таныштырырга бурычлы.

Тикшерү барышында Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламентның 4 бүлегендә күрсәтелгән, юридик затларның, шәхси эшкуарларның инвестиция программаларын үтәве турында нәтиҗә ясау, шулай ук тикшерү нәтиҗәләре буенча дөрес карар кабул итү өчен әһәмияте булган документлар тикшерелә.

Юридик затларның, шәхси эшкуарларның исәпкә алу документларының колачлылык дәрәҗәсенә карап, документларга тоташ яки сайланма тикшерү уздырылырга мөмкин.

Тоташ тикшерү методы кулланылган очракта, юридик затларның, шәхси эшкуарларның исәпкә алуның билгеле бер бүлегенә һәм тиешле хисап чорына караган барча беренчел исәпкә алу документлары, шулай ук әлеге документларда, исәпкә алу регистрларында рәсмиләштерелгән хуҗалык операцияләренең чагылдырылышы тикшерүгә дучар ителә.

Сайланма тикшерү методы кулланылган очракта, юридик затларның, шәхси эшкуарларның исәпкә алу документларының тикшерүчеләр тарафыннан хуҗалык операцияләренең әһәмиятен исәпкә алып, шулай ук очраклы рәвештә сайлап алу методларын кулланып сайлап алынган бер өлеше тикшерелә.

Исәпкә алу документациясенең колачлылык дәрәҗәсе тикшерүчеләр тарафыннан мөстәкыйль, тикшерелергә тиешле документлар күләменә, юридик затларның, шәхси эшкуарларның бухгалтерлык исәбе торышына карап һәм башка шартларга бәйләп билгеләнә.

Тикшерү уздыру барышында юридик затларның, шәхси эшкуарларның инвестиция ресурсларын максатчан куллануына карата таләпләрне үтәве билгеләнә.

Тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар контроль буенча түбәндәге чараларны үткәрәләр:

1) алдагы тикшерүдә ачыкланган инвестиция ресурсларыннан максатчан файдаланмау очракларының бетерелүенең тулы булуын тикшерәләр;

2) бухгалтерлык хисаплылыгында чагылдырылган күрсәткечләрнең инвестиция программаларын һәм алар буенча хисаплар формалаштырганда кулланылган план-исәпләмә күрсәткечләренә туры килүен тикшерәләр;

3) тикшерелә торган оешманың эшчәнлеген сыйфатлый торган документларны һәм материалларны тикшерү предметын гыйбарәт итүче мәсьәләләр буенча карап тикшерәләр;

4) зарурлык булганда – инвестиция программасы кысаларында финанслануы тәэмин ителә торган электр һәм җылылык энергиясе чыганакларын һәм (яки) электр һәм җылылык челтәрләрен төзү, үзгәртеп кору һәм (яки) модернизацияләү субъектларына карата аларны билгеләнгән тәртиптә эксплуатациягә кертү предметына карата тикшерү үткәрәләр;

5) зарурлык булганда – тикшерү предметын тәшкил итүче мәсьәләләр буенча тикшерелә торган оешма эшчәнлеген сыйфатлый торган документларга һәм материалларга бәйсез экспертиза уздыралар.

Үтәү вакыты: тикшерү уздыру турында боерыкта билгеләнгән тикшерү уздыру срогы дәвамында, ләкин 20 эш көненнән артык түгел.

Гамәлнең нәтиҗәсе: контроль буенча үткәрелгән чаралар.

5.28. Әгәр шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының булмый торуы сәбәпле, яисә юридик затның, шәхси эшкуарның фактта эшчәнлеге гамәлгә ашырылмау сәбәпле, яисә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки бүтән вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китереп чыгарган башка гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында урынга чыгып планлы тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты, аны үткәрүнең мөмкин булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты тиешле тикшерүне үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр планына кертмичә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

5.29. Җаваплы башкаручы үткәрелгән контрольлек чаралары нигезендә РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча ике нөсхәдә тикшерү актын төзи.

Тикшерү нәтиҗәсендә бәя билгеләүнең билгеләнгән тәртибе бозылуларны ачыклаган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

- тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган бозуларны тикшерү актында терки;

- үз компетенцияләренә кагыла торган өлештә бозуларны тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган күрсәтмәләрнең проектлары нигезендә, бетерү чорларын күрсәтеп, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында Дәүләт комитетының җыелма күрсәтмәсе проектын әлеге Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча әзерли һәм Дәүләт комитеты рәисенә кул кую өчен җибәрә. Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән вакытларда үтәлүен тикшереп тору, бүлек компетенциясе кысаларында, тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган юридик затларның вазыйфаи затларының (вәкилләренең), шәхси эшкуарларның аңлатмалары;

тикшерү нәтиҗәләренә бәйле булган бүтән документлар яисә аларның күчермәләре.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә тегеп куя һәм аны Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы хәбәр Дәүләт комитеты эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын кулга тапшыру турында белдерүле заказлы хат итеп һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында (тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон формада хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булу шарты белән) күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- тикшерү актын формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклау: билгеләнгән тәртиптә аны Дәүләт комитеты архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән чорлар дәвамында.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклана.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.30. Җаваплы башкаручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затта, шәхси эшкуарда булган очракта, урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу.

5.31. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: мәгълүматны Дәүләт сайтында урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат кертү – билгеләнгән срокларга туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерүне башкару нәтиҗәләре хакында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган һәм бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат.

**«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш документлар тикшерү үткәрү» административ процедурасы**

5.32. «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен шушы Регламентның 2.4.7 пунктында күрсәтелгән очраклар нигез булып тора.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасы гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

- тикшерүне үткәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларны билгеләү;
- тикшерү үткәрү турында боерык рәсмиләштерү;
- тикшерүне үткәрү;
- тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.33. Дәүләт комитеты бүлекләренең үз вәкаләтләре кысаларында тикшерүне үткәрүче башлыклары юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү өчен юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата документар тикшерү үткәрүгә вәкаләтле булган вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затларның исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.34. Әлеге Регламентның 5.19 пунктында билгеләнгән тәртиптә юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) боерыгын әзерләү.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.35. Җаваплы башкаручы юридик затларга, шәхси эшкуарларга, планнан тыш документар тикшерү уздырылуы турында боерык күчермәсен кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы яки мөмкин булган башка төрле ысул (факсимиль элемтә, электрон почта, кулга тапшыру турында тамгалап кулдан) белән җиткереп, планнан тыш документар тикшерү уздырылуы турында хәбәр итә.

Юридик затка, шәхси эшкуарга – үзкөйләнешле оешма әгъзасына карата тикшерү үткәрелгән очракта җаваплы башкаручы шулай ук, планнан тыш документар тикшерүне үткәргәндә аннан вәкил катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән планнан тыш документар тикшерү уздырылуы турында боерык күчермәсе.

5.36. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар, боерык күчермәсен алган мизгелдән башлап ун эш көне эчендә, Дәүләт комитетына планнан тыш документар тикшерү үткәрү турындагы боерыкта күрсәтелгән документларны җибәрергә бурычлы.

Гарызнамәдә күрсәтелгән документлар мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының тиешенчә имзасы белән таныкланган күчермәләре рәвешендә тапшырыла. Юридик зат, шәхси эшкуар гарызнамәдә күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

Әгәр дә Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, Дәүләт комитетына тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Дәүләт комитеты юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) бүтән органнарыннан, муниципаль контроль органнарыннан алынырга мөмкин булган белешмәләрне һәм документларны таләп итәргә хокуклы түгел.

Дәүләт комитеты, тикшерүләрне оештырганда һәм уздырганда, түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яисә) мәгълүматларны шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә сораталар һәм алалар.

5.37. Юридик затларның, шәхси эшкуарларның документларында бәян ителгән белешмәләрне бәяләү, тапшырылган документлардагы кисәтүләргә каршы юридик затларның, шәхси эшкуарларның аңлатмаларын карап тикшерү шушы Регламентның 5.22 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.38. Тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны карау нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы ике нөсхәдә РФ Икътисадый үсеш

министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы белән расланган формада тикшерү актын төзи.

Тикшерү нәтиҗәсендә бәя билгеләүнең билгеләнгән тәртибе бозылуларны ачыклаган очракта, җаваплы башкаручы түбәндәге гамәлләрне башкара:

- тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган тикшерү нәтиҗәләре нигезендә ачыкланган бозуларны тикшерү актында терки;

- үз компетенцияләренә кагыла торган өлештә бозуларны тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан тапшырылган күрсәтмәләрнең проектлары нигезендә, тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган бозуларны туктату (бетерү) турында Дәүләт комитетының җыелма күрсәтмәсе проектын әлеге Регламентка 3 нче кушымтада бирелгән форма буенча әзерли һәм Дәүләт комитеты рәисенә кул кую өчен җибәрә. Дәүләт комитеты күрсәтмәсенең билгеләнгән вакытларда үтәлүен тикшереп тору, бүлек компетенциясе кысаларында, тикшерүне үткәрү вәкаләте бирелгән вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) җаваплы башкаручы эшкә тегеп куя һәм аны Дәүләт комитетына билгеләнгән тәртиптә тапшырганчыга кадәр саклый, икенчесен (кушымталарының күчермәләре белән берлектә) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү акты белән танышып чыгу турында яисә танышып чыгудан баш тарту турында имза куйдыртып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы хәбәр Дәүләт комитеты эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы акты төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелүче затка күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры (әгәр дә актны төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең,

сынауларның, махсус тикшеренүләрнең, экспертизаларның нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алу зарур булса, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган чорда төзелә);

- тикшерү актын кулга тапшыру турында белдерүле заказлы хат итеп һәм (яки) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында (тикшерелә торган затның төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында электрон формада хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булу шарты белән) күрсәтелгән документның алынуын раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрү: тикшерү актын төзегәннән соң бер эш көне эчендә;

- формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә аны билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитеты архивына тапшырганчыга кадәр норматив актларда билгеләнгән сроклар дәвамында саклау.

Гамәлнең нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, аның берсе юридик затка, шәхси эшкуарга тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе эшкә тегеп куелган һәм билгеләнгән тәртиптә формалаштыру урыны буенча Дәүләт комитетының структур бүлекчәсендә саклана.

Үзләренә карата тикшерү үткәрелгән юридик зат, шәхси эшкуар, тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә Дәүләт комитетына тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта Дәүләт комитетына тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

5.39. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: мәгълүматны Дәүләт сайтында урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат кертү – билгеләнгән срокларга туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерүне башкару нәтиҗәләре хакында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган һәм бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат.

**«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасы**

5.40. Әлеге Регламентның 2.4.7 пунктчасында күрсәтелгән очраклар «Юридик затларга, шәхси эшкуарларга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасын үткәрә башлау өчен нигез булып тора, шулай ук әгәр дә документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да:

1) эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турындагы хәбәрдә һәм юридик затларның, шәхси эшкуарларның Дәүләт комитеты карамагында булган бүтән документларында бәян ителгән белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп белү;

2) юридик затлар, шәхси эшкуарлар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контроль буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү» административ процедурасы шушы Регламентның 5.17 пунктында күрсәтелгән административ гамәлләр тәртибенә туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.41. Еллык План нигезендә үз компетенцияләре кысаларында тикшерү үткәрүче Дәүләт комитеты бүлекләре башлыклары юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затларны һәм җаваплы башкаручыны билгели.

Әгәр дә урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәргәндә экспертлар, экспертлык оешмалары катнашында контроль чараларын үткәрү таләп ителсә, Дәүләт комитеты рәисе аларга карата тикшерү үткәрелүче юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән граждани-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы һәм тикшерелә торган затларның аффилир затлары булмаган экспертларны, экспертлык оешмалары вәкилләрен җәлеп итә.

Үтәү вакыты: планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән башлап бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар (экспертлар, экспертлык оешмалары вәкилләре) исемлеге, җаваплы башкаручы.

5.42. Әлеге Регламентның 5.19 пунктында билгеләнгән тәртиптә юридик затка, шәхси эшкуарга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисенең (рәисе урынбасарының) боерыгын әзерләү.

Үтәү вакыты: урынга чыгып планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен вәкаләт бирелгән вазыйфаи затлар билгеләнгәннән соң өч эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында Дәүләт комитеты рәисе (рәисе урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык.

5.43. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәреләчәге турында, шушы Регламентның 2.4 пунктындагы 2.4.7 пунктчасының 2) пункт өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә үткәрелә торган урынга чыгып планнан тыш тикшерүдән кала, теләсә нинди үтемле ысул белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган һәм юридик затның, шәхси эшкуарның электрон почта адресына җибәрелгән электрон документ рәвешендә хәбәр итә, әгәр дә мондый адрес тиешенчә юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элегрәк юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан Дәүләт комитетына тапшырылган булса.

Үтәү вакыты: тикшерүне үткәрә башлаганчыга кадәр егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: урынга чыгып планнан тыш тикшерү уздыру турында юридик затка, шәхси эшкуарга җибәрелгән хәбәр.

5.44. Урынга чыгып планнан тикшерүне үткәрү шушы Регламентның 5.20 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Әгәр дә шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының булмавына бәйле рәвештә, яисә юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең фактта башкарылмавына бәйле рәвештә, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең яки башка вазыйфаи затының бүтән төрле, тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында планнан тыш урынга чыгып тикшерүне үткәрү мөмкин булмаса, җаваплы башкаручы, аны үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаручы сәбәпләрне күрсәтеп, тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы хакында акт төзи. Бу очракта Дәүләт комитеты урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы хакында актны төзегән көннән башлап өч ай дәвамында мондый юридик затка, шәхси эшкуарга карата, юридик затка, шәхси эшкуарга алдан хәбәр итмичә, урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү хакында карар кабул итәргә хокуклы.

5.45. Тикшерү актын төзү, тикшерү актын юридик затка, шәхси эшкуарга тапшыру, тикшерү барышында ачыкланган бозу фактларына карата законнарда

каралган чараларны күрү шушы Регламентның 5.23 пунктына туры китереп гамәлгә ашырыла.

5.46. Җаваплы башкаручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планнан тыш тикшерү турында, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне үткәрә башлау һәм тәмамлау даталары, аны үткәрү вакытлары, тикшерүнең төре, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, ачыкланган бозулар һәм бирелгән күрсәтмәләр турындагы белешмәләрне үз эченә алган язуны терки, шулай ук тикшерүне үткәргән вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм аларның имзалары күрсәтелә.

Үтәү вакыты: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры.

Гамәлнең нәтиҗәсе: юридик затларның, шәхси эшкуарларның тикшерүләрне исәпкә алу журналында (ул булган очракта) урынга чыгып үткәрелгән планлы тикшерү турында теркәлгән язу.

5.47. Административ процедура тәмамланганнан соң җаваплы башкаручы Дәүләт комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә тиешле мәгълүматны, планлы документар тикшерүне үтәү нәтиҗәләрен теркәү максатында, Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру турында хезмәт язуын җибәрә.

Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи заты 294-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына, РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертә.

Үтәү вакыты: мәгълүматны Дәүләт сайтында урнаштыру – тикшерү акты имзаланганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча;

тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча үрнәк болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат кертү – билгеләнгән срокларга туры китереп.

Гамәлнең нәтиҗәсе: планлы документар тикшерүне башкару нәтиҗәләре хакында Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган һәм бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән мәгълүмат.»;

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Әгәр язмача шикаятьтә юридик затның аталышы (мөрәҗәгать итүче юридик зат булганда), шикаятьне җибәргә мөрәҗәгать итүченең фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр дә күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче,

кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр язмача шикаятьтә цензурасын яки мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять анда куелган мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хокуктан явызларча файдалануның ярамаганлыгы турында хәбәр ителә.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә.

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитетының вазыйфаи заты яки моңа вәкаләтле заты күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Дәүләт комитетына яисә Дәүләт комитетындагы шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаять белән мөрәҗәгать итүнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән мондый язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Дәүләт комитетына яки Дәүләт комитетының вазыйфаи затына, 59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алучы язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелучы сорауга җавап урнаштырылган Дәүләт комитетының рәсми сайтының электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр дә шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә

куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне Дәүләт комитетына яисә аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.».

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис в.б. А.Л.Штром